**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы 3 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. 2020 елның 1 октябреннән «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» 2006 елның 27 мартындагы ПУ-122 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 29 декабрендәге ПУ-597 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-538 номерлы, 2008 елның 28 апрелендәге ПУ-168 номерлы, 2010 елның 6 маендагы ПУ-295 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-461 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-230 номерлы, 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы, 2013 елның 2 августындагы ПУ-705 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге ПУ-1031 номерлы, 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-348 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-295 номерлы һәм 2020 елның 11 мартындагы ПУ-164 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттырырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен исәпләгәндә, әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы министрын айлык акчалата бүләкләү күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм ул 40 170 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында»

2006 елның 27 мартындагы ПУ-122 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 29 декабрендәге ПУ-597 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-538 номерлы, 2008 елның 28 апрелендәге ПУ-168 номерлы, 2010 елның 6 маендагы ПУ-295 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-461 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-230 номерлы, 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы, 2013 елның 2 августындагы ПУ-705 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге ПУ-1031 номерлы, 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-348 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-295 номерлы һәм 2020 елның 11 мартындагы ПУ-164 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункты өстәп, үзгәреш кертергә:

«$9^1$. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата түләүләр, айлык акчалата бүләкләүләр күләме арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованияләре күләмендә финанслауны башкарырга.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 15 август
№ ПУ-497